Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл
башкарма комитеты

КАРАР

«16» декабрь, 2025 ел № 101

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитетның 2021 елның «25» мартындагы 9 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитетның «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның «25» мартындагы 9 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 июнендәге 42 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлек 2.5 пунктының 4 пунктчасында «гариза бирүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «гариза бирүче тарафыннангариза бирүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен тапшыруу һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 бүлекнең 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасын өстәргә:

«4.1. Гариза бирүче булмаган затның шәхси белешмәләре ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы аша тапшырылган очракта, гариза бирүче өчен башкарма хакимиятнең федераль органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен мондый белешмәләрне чагылдырмыйча башкару өчен, күрсәтелгән максатларда мондый затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

Җитәкче: Р.Р.Хәнәфиев